• ЧАРАЛАР

# Халкы өчен җан атып




**Альбина Нурмөхәммәтова әнисенә багышланган стенд янында.**

**Талантлы укытучы, актив җәмәгать эшлеклесе, үткен каләмле хәбәрче, 1971-1975 елларда республиканың Югары Совет депутаты, зыялы шәхес Әнисә Нурованың исеме халык хәтерендә саклана.**

Агымдагы елда аның туууна 100 ел булды. Бу уңайдан кызы Альбина Нурмөхәммәтова әнисенең матбугатта басылган язмаларын туплап “Халкым өчен җан аттым” дип аталган китап бастырды. Шул китап туена Әнисә Нурованың мәкаләләрендә хезмәтләре, тормышлары яктыртылган тере геройлар – Таңатар мәктәбендә озак еллар үз эшен яратып башкарган укытучылар, ул укыткан укучылар, төрле хезмәт ияләре, язмалары геройларының балалары, оныклары җыелды.

Бер тында үтте ул кичә. Әнисә Шакир кызы турындагы истәлекләр барланды, китапка күзәтү ясалды. Лаеклы ялдагы укытучылар Әлфир Мөхәмәтдинов һәм Илгизә Әхиярова коллегалары турында якты истәлекләре белән бүлеште. Әлфир Сәләхетдин улы хәтта Әнисә Шакир кызының укучысы да булган икән. Сугыш чоры баласы буларак, ул чактагы авыр тормышны да, укыту үзенчәлекләрен дә искә төшереп үтте ветеран.

Шулай ук туганнары, авылдашлары да чыгыш ясадылар, хатирәләрен уртаклаштылар, барысын да санап тору мөмкин дә түгел. Әмма шунысын ассызыклап үтәргә кирәк, кичәгә килгәннәрнең Әнисә Шакир кызын никадәрле ихтирам иткәне, аны сагынып искә алуы һәр чыгыштан, һәр әйткән сүздән аңлашылып торды. Ә 86 яшьлек Лена апа Фазлетдинованың гармунда уйнавы кичәгә аеруча ямь өстәде.

– Безнең туебызда минем гармун уйнаганны күреп, Әнисә апа: “Апаем, бу һөнәреңне ташлама яме”, – дип хуплаганы бүгенгедәй хәтеремдә. Аның якты истәлегенә булсын әле, – дип, яшьлек көйләрен сыздырды ул.

“Исламия”, “Яшьлек” вокаль ансамбльләре, Илшат Төхбәтуллин, Гөлшат Камалтдиновалар башкаруындагы җырлар да кичәне бизәде. Җырларның байтагы Альбина Нурмөхәммәтованың сүзләренә язылуын да әйтеп үтми булмый.

Әйткәндәй, Альбина Сафа кызы үзе дә әнисе турындагы истәлекләр белән бүлеште, туган якка багышланган шигырьләрен укып ишеттерде.

Китапка күчик әле. “Халкым өчен җан аттым” дип аталган бу китап җиде бүлектән тора. “Мәктәп – белем йорты, тәрбия эшенең үзәге”, “Хезмәт ул – зур көч”, “Кешене хезмәт бизи”, “Язмаларда кеше язмышлары” бүлекләрендә Әнисә Нурованың 1958 елдан 1995 елга кадәр матбугатта басылган мәкаләләренең бер өлеше кертелгән. Нигездә үзебезнең “Алга”да басылган мәкаләләр тәшкил итә. Шунысы куанычлы, бу мәкаләләрдәге кешеләрне таныйсың, аларның балалары, оныклары безнең арада һәм алар да әти-әниләренең, нәнәй-картәтиләренең яхшы эшләрен дәвам итә. Ялгышмаган Әнисә Шакир кызы бу хезмәт ияләре турында гәзит битләрендә яктыртып.

Мәкаләләр арасында тәнкыйть утында тотканнары да, авыллардагы проблемаларны күтәргәннәре дә шактый. Китапның соңгы, җиденче бүлегендә нәкъ менә шул авыллар арасындагы юлсызлык, фельдшер пункты булмау, Чалкакта участок дәваханәсен киңәйтү, мәктәп бинасы төзетү, Чапаев исемендәге колхозга автомобиль һәм телефон элемтәсе юллау һ.б бик күп мөрәҗәгатьләр белән Әнисә Нурованың республика җитәкчелегенә, министрлыкларга язган хатлары, алардан алган җаваплары кертелгән. Чынлап та бар гомерен халкы өчен яшәгән ул.

“Халык ышанычын ул аклады”, “Ул безнең күңелләрдә яши” дип аталган бүлекләргә Әнисә Шакир кызы турында язылган мәкаләләр, истәлекләр кертелгән. Бу язмалар төрле елларда һәм төрле кешеләр тарафыннан язылса да, асылы бер: Әнисә Нурова – ачык күңелле, кешелекле, кечелекле хатын-кыз, ихтирамлы укытучы, зыялы шәхес.

Кичәдәдә китапка, аның бүлекләренә Гөлшат Яләева байкау ясады. Ә авыл биләмәсе башлыгы Алсу Төхбәтуллина исә бу китап Таңатар авылының тарихын саклаучы, кешеләрен данлаучы ядкәр итеп кабул итүләрен әйтеп, Альбина Сафа кызына якташлары исеменнән зур рәхмәтләрен җиткерде.

Шәхсән мин үзем, район гәзитенең баш мөхәррире буларак, бу “Халкым өчен җан аттым” китабын “Алга”бызның киләсе елда көтелгән 95 еллык юбилеена бүләк итеп кабул иттем. Чөнки бу китапның яртысыннан күбрәк өлешен безнең гәзитебездә төрле елларда басылган мәкаләләр тәшкил итә.

Ташка басылган – мәңгелек, ул югалмый, гасырларга саклана. Әнисә Шакир кызы Нурова яхшы гамәлләре белән исемен халык хәтеренә язып калдырган.

**Венера АРСЛАНОВА.**



**– Безнең туебызда минем гармун уйнаганны күреп, Әнисә апа: “Апаем, бу һөнәреңне ташлама яме”, – дип хуплаганы бүгенгедәй хәтеремдә. Аның якты истәлегенә булсын әле, – дип, яшьлек көйләрен сыздырды Лена апа Фазлетдинова.**

• УҢГАННАРНЫ МАКТЫЙБЫЗ

# Чәчәкләр – тормыш бизәге



Илмира Дәүләтбаева

Җәй җитүгә күпләр йорт тирәләрен, бакчаларын, өй алларын матурлый башлый, гөлбакчага әйләндерә. Үз куллары белән гөл-чәчәкләрдән матурлык тудыручы, кешеләргә гүзәллек бүләк итүчеләрнең күңеле дә матур буладыр. Борайда да тырышлар, егәрлеләр матур итеп дөнья көтәргә әмәлен таба. Авылның күркәмлеген, матурлыгын саклаган уңганнар йорт тирәләрен аллы-гөлле шау чәчәккә күмде. Илмира һәм Фәвәрит Дәүләтбаевлар да елның-елында ихаталарында нинди генә чәчәкләр үстермиләр. Иртә яздан кара көзгә кадәр ике уңган бер булып бакчада матурлык тудыралар. Ә кышларын исә Илмира өендә төрле чәчәкләр, гөлләр үсентеләрен алдагы елга бакчага чыгарырга әзерли.

Хуш исе башны әйләндергән лилияләр, нәзәкатьле дә, горур да гөлчәчәкләр, менә-менә ачылырга торган хризантемалар, таҗларына көмеш тамчысы кебек күз яшедәй җемелдәгән чәчәкләр, назлы ясминнәр – барысы да күзләрне иркәләп, нур сибәләр. Бакчаны төрлечә бизәп була, корылмалар эшләп тә, төрле әкият геройлары, кечкенә бакча сыннары белән дә. Ә менә Дәүләтбаевларның бакчасында чәчәкләр төрле төсләре белән сокландыра. Төрле төстәге петунияләр, гортензияләр, әрсез бәрхет гөлләре, кашкарыйлар, гладиолуслар, дәлияләрдән тыш дистәләгән таныш булмаган чәчәкләр үстерә алар.

– Кечкенә чакта кешеләрнең тәрәзә төпләрендә гөлләр күрсәм, кабат-кабат барып карый идем. Хәзер үзем үстерәм, шөкер. Гөлләр белән сөйләшеп, кәефләрен аңлап, вакытында ашласаң, алар сине матур чәчәкләре белән сөендерә. Эшләгән вакытта чәчәкләрне тәрбияләргә вакыт бик юк иде. Хәзер исә, лаеклы ялда булгач, көне буе бакчада. Кайчак вакытның күпме икәнен дә онытып җибәрәм хәтта. Үсемлекләр сабый баладай даими тәрбия сорый. Язын-җәен ашлама кертү, су сибү, коры-сарыны җыештыру, эсседән, кырау сугудан, җил-яңгырдан саклау, гөмбәчек кебек авырулардан эшкәртү гамәлләре булса, салкыннар якынлашуга гөлләрне дөрес кышлату турында хәстәрлек күрергә вакыт җитә. Дөрестән дә, бакчада эш бер дә бетми, иртәнге алтыдан торып, үсемлекләрне карыйм, кич тагын шулар янында кайнашам, – ди Илмира.

Һәр чәчәкне, куаклыкны кадерләп кенә, иркәләп үстерә алар. Салкын чорда чәчәкләрнең бер өлеше подвалда саклана.

Менә шулай дөньяларын ямьләп, үзләренә шөгыль табып яши безнең элемтә узелы ветераннары. Гомумән алганда элемтә ветераннары бик актив тормыш белән яшиләр. Аларның күбесе матурлык, тәртип, чисталык яраталар. Шуңа күрә дә районда узган һәр өмәдә актив катнашабыз. Үзебезнең элек эшләгән бинабыз янын ямьләүдә дә үз өлешебезне кертәбез.

**Дәрвис ТАҖЕТДИНОВ,**
**элемтә узелы ветераннар советы рәисе.**